Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы

422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

**КАРАР**

“ 07 ” март 2019 ел № 1

**Гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәре муниципаль берәмлегенең 13.09.2018 ел, №99 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. 2019 елның 10 апреленә «Арча шәһәре муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 22.11.2018 ел, №106 Арча шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. «Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 22.11.2018 ел, №106 Арча шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны 10.04.2019 елда 17.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 нче йорт адресы буенча үткәрергә.

3. «Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә карата тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар язма рәвештә 10.04.2019 елның 17.00 сәгатькә кадәр ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресына җибәрелә дип билгеләргә (тел. 884366 3 16 25).

4. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында 22.11.2018 ел, №106 Арча шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарны һәм карар проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки «Арча хәбәрләре» газетасында, Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р .Ф. Касыймовка йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев